РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

27 июня 2024 ел №252

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы депутатларының, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайлап куелган җирле үзидарә вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 149 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 149 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карарының 1 өлешендәге 3 абзацын (район

Советының 2020 елның 29 октябрендәге 8 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 140 номерлы, 2022 елның 28 декабрендәге 156 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрп белән) бәян итәргә:

1.1. Карарның 1 пунктының 4 абзацын бәян итәргә: «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең хезмәт хакы күләме 13323 сум тәшкил итә»;

1.2. 1 нче кушымтаның III бүлегенең 1 нче пунктындагы 6 нчы пунктчасын бәян итәргә: «6) айлык акчалата бүләкләү вазифа окладының 41 процентыннан артмаган күләмдә».

1.3. 2 нче кушымта «Муниципаль район башлыгының, депутатларның, муниципаль районда даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының, муниципаль районның Контроль-хисап палатасы рәисенең акчалата бүләкләү күләме» кушымтага ярашлы рәвештә яңа редакциядә бәян ителергә тиеш.

1.4. 7 нче кушымтасында 1 нче пунктны бәян итәргә: «1. Муниципаль хезмәткәрләргә премиядән тыш ай саен акчалата бүләкләүләр дә түләнә. Муниципаль хезмәткәрләргә айлык акчалата бүләкләү җирле үзидарә органы җитәкчесе карары белән вазыйфаи хезмәт хакының 41 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә.

2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башлыгы урынбасарына, Совет рәисе урынбасарына йөкләргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советының 2018 елның 24 апрелендәге 149 номерлы карарына 2 нче кушымта

Кушымта
(Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2024 елның 27 июнендәге 252 номерлы карары редакциясендә)

Муниципаль район башлыгының, депутатларның, муниципаль районда даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының, муниципаль районның Контроль-хисап палатасы рәисенең акчалата бүләкләү күләме

| Вазыйфалар атамасы | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 35272 |
| Башлык урынбасары | 31745 |
| Депутатлар | 17297 |
| Сайланган җирле үзидарә органнары әгъзалары | 14697 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 31745 |